**«СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**

**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ**

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

КАРАР

№ 1 «14» октябрь 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәсен раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Мөслим муниципаль районының «Симәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Симәк авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында», Нигезләмәсен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Симәк авыл җирлеге Башлыгы Р.Ә.Садертдинов

Мөслим муниципаль районы
Симәк авыл җирлеге Советының
14.10.2019 ел
1 номерлы карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы (шәһәр округы) җирлеге составына керүче торак пунктларда (алга таба – шәһәр округы) гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасының Мөслим муниципаль районы (шәһәр округы) Симәк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халык җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Халык җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан үткәрелә.

1.6. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап уздырыла.

## Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

Җирлекнеә (муниципаль районның) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, әгәр торак пункт чикләрен үзгәртү башка җирлек (муниципаль район) территориясенә күчерүгә китерсә;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

гражданнар җыенын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гамәлгә ашыра торган җирлектә, сайлау хокукына ия булган җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артык кеше булса, җирлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турында мәсьәлә буенча;

Мунципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча;

җирлек составына, шәһәр эче районына, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориягә, муниципаль округ, шәһәр округы йә муниципаль район чикләрендә авылара территориягә керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук яңа оешкан җирлектә, сайлау хокукына ия булган кешеләр саны 300 дән артмаган булса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

авыл халкының түбән тыгызлыгы яки кыен урнашкан җирлектә халык саны 100 кешедән артмаган булса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча эш алып барыла;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл җирлеге старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча.

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин (муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздырганда.)

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Җыен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

**2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе**

Гражданнар җыены үткәрү инициативасы:

2.1. Торак пункта гражданнар җыеннарын үткәрү инициативасы белән чыга алалар::

- Җирлек Башлыгы;

- гражданнар җыенында катнашу хокукына ия булган 10 кешедән дә ким булмаган, сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүче гражданнар (ягъни, Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән (18 яшькә җиткән даими яки нигездә яшәүче) һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия булган гражданнар).

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имза битләрендә ***(1 нче кушымта)*** яки гражданнар җыенын үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында карар кабул ителгән инициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш. Беркетмәдә түбәндәге мәсьәләләр чагылыш табарга тиеш:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;

гражданнар җыенын чакырту турында инициативаны хуплаучы һәр гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне; паспорт сериясе һәм номеры, яки аны алыштыручы документ, яшәү урыны адресы; аның имзасы һәм имза куелу вакыты.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки нигездә яшәүче, торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санынннан 5 процент тәшкил итә, ләкин 10 имзадан да ким була алмый.

2.4. Язылу кәгазьләре имзалар җыючы зат тарафыннан таныклана, таныклау датасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган датасын, паспорт номерын һәм сериясен, яки аны алыштыручы документын, яшәү урынын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

**Гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул итү тәртибе**

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән (2 нче кушымта), ә

муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы аның максатка ярашлы булмавы сәбәпләре буенча гражданнар җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә (гражданнар җыены этаплары) Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыены мәсьәләсе конкрет һәм ачык итеп формалаштырылырга тиеш, ягъни аңа бары тик бер мәгънәле җавап кына бирергә мөмкин булырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Муниципаль берәмлек башлыгы карарында яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында гражданнар җыенын уздыру турында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында белешмәләр.

2.9. Гражданнар җыенын (башкарма-боеру органы) әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе, муниципаль берәмлек башлыгы карары яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә яисә гражданнар җыенын үткәрү турында муниципаль берәмлек башлыгы карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлекләрен төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; гражданнар җыены турында муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән хәбәр итә ***(4 нче кушымта).***

Муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

***2.9.1. Гражданнар җыены барышында торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм халык җыенын үткәрү датасын билгеләү территориаль, вакытлы билгеләр, шулай ук башка очракларда мөмкин.***

***2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 нчы кушымталар).***

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыены үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә ***(халык җыены этаплары).*** Гражданнар җыенын ***(гражданнар җыены этапларын)*** билгеләү турында карар, гражданнар җыенын ***(гражданнар җыены этапларын)*** үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыены ***(гражданнар җыены этапларын)*** үткәреләсе көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.

***Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү вакыты һәм урыны Башкарма комитет яки халык җыены үткәрү карарында, яисә авыл җирлеге Советы карарында күрсәтелә***

***2.9.4. Халык җыенын этаплап уздырган очракта, җыен, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмый, этаплап уздырыла. Халык җыены этапларын күчергәндә, җыенны үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, закон нигезендә җыен үткәрелергә тиешле айлык чорны исәпкә алып, күчерү турында Карар кабул ителергә тиеш.***

2.9.5. Халык җыенында катнашучы һәр кеше, гражданнар җыенына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә әлеге Нигезләмәнең 2.9. пунктында күрсәтелгән гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хоакуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә, халык җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Күчерү турындагы карар, халык җыенын

уздыру датасы билгеләнгән датага кадәр, 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтле заты тарафыннан торак пунктта яшәүче сайлау хокукына ия булган кешеләрне теркәү исемлегенә кертү теркәвен үтәләр. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга шулай ук җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнарга да хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка керү рөхсәтле. Җыенда күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлеге белән бәйле булса, предприятие, учреждение җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнаша ала.

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенда катнашырга мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслау булып гражданинның шәхесен раслаучы документның булуы хезмәт итә ала (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һ. б.)

3.5. Гражданнар җыены сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашса хокуклы санала Кворум булмаганда, гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелмәскә тиеш.

***3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыены җыенның аерым этапларында гражданнарның төрлечә килгән очракта да хокуклы, чөнки аннан соң барлык уздырылган этаплар йомгаклары буенча тавышларны санала, ягъни мондый җыен бердәм булып кала.***

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә **(вариант буларак: форма гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).**

3.8. Гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга яшерен тавыш бирүне уздырганда тавыш бирү өчен бюллетень ***(7 нче кушымта)*** бирелә .

3.9. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Гражданнар җыены Сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый.

***Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән дә ким була алмый.***

***Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.***

***Хисап комиссиясе:***

1) ***торак пунктта яшәүчеләр җыенына килүче гражданнарны теркәүнең дөреслеген, кирәк булганда, аларның гражданнар җыены эшендә катнашу хокукын тикшерә;***
2) ***гражданнар Җыенының кворумын билгели <u>(гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);</u>***
3) ***тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;***
4) ***тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый <u>(гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);</u>***
5) ***тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи <u>(гражданнар җыены йомгаклары буенча);</u>***
6) ***рәислек итүчегә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материаллар (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.***

3.11. Гражданнар Җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә чакырылыш инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

***3.12. Гражданнар җыены вакытында шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат (гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән) рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы..***

***3.13. Гражданнарның этаплап җыенында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.***

***Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены этабында кабул ителә (вариант буларак: тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).***

***3.14. Гражданнар җыенын уздыру этапларының һәркайсында хисап комиссиясе арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер әгъзасы сайлана, алар кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк.***

3.15. Җыен рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне хуплый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.16. Гражданнар җыенында сәркатип тарафыннан беркетмә алып барыла, анда гражданнар җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны ***(8 нче кушымта)*** күрсәтелә.

***3.17. Халык җыенын этаплап уздырганда гражданнар Җыенының һәр этабында беркетмәләр (9,10 нчы кушымталар) алып барыла, алар соңыннан гражданнар Җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә (11 нче кушымта).) шулай ук хисап комиссиясе беркетмәләредә алып барыла (№12,13 кушымталар), алар да шулай ук җыенның һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә (№14 беркетмә).***

***3.18. Гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларының датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында белешмәләр, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре бар. Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куя торган (халыкка игълан итү максатында алга таба рәсми бастырып чыгарыла торган) гражданнар җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.***

3.19. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыен сщркатибе тарафыннан кул куела һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

***3.20. Гражданнар Җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, халык җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан***

***гражданнарның гомуми саны, унай һәм каршы бирелгән тавышларның гомуми саны, аңа каршы тавышларның гомуми саны.***

***3.21. Йомгаклау беркетмәсенә хисап комиссиясе рәисе һәм әгъзалары тарафыннан кул куела һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.***

## 4. Халык җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала, әгәр җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсәләр.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә, яисә суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең турыдан-туры ихтыярый белдерү юлы белән кабул ителгән карарын гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) таләп ителсә, күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) аның компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты, гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә, тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

### Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларның үтәлмәве закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

**Гражданнар җыены инициатив төркем инициативасы белән үткәрелгән очракта**
**Проект**
**Татарстан Республикасы Мцслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 5 нче кушымта**

**КАРАР**

**14.10. 2019ел** **№ 1**

**Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге______________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, __________________ муниципаль районы (« _________________ шәһәре» муниципаль берәмлеге), ________________ авыл җирлеге Уставының ______ нче маддәсе нигезендә, __________ муниципаль районы __________ авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

***1.*** _____________ муниципаль районы җирлеге («__________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) ____________ авыл _____________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча *гражданнар җыенының* ***беренче этабын*** ______ елның ______________ 00 сәг. 00 мин.билгеләргә.
***2.*** _____________ муниципаль районы җирлеге («__________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) ____________ авыл _____________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча ***гражданнар җыенының икенче этабын*** ______ елның ______________ 00 сәг. 00 мин.билгеләргә.
3. ***Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген (территориаль, вакытлыча яки башка билге буенча) бүлү тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турындагы муниципаль актта күрсәтелә.***
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 20_______ елда __________муниципаль районы __________авыл җирлеге («___________шәһәре» муниципаль берәмлеге) ___________ территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә ______________________________________________(үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә) тыш, _______ сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча тотуга ризамы?

« ӘЙЕ» «ЮК»

5. Әлеге карарны ____ көн эчендә ________________ авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

______________________ авыл җирлеге
Советы Рәисе ФИО ________

**Проект**
**(муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы буенча гражданнар җыенын этаплап үткәргән очракта)**
**Кушымта № 6**

**«______________ муниципаль районы («__________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) ______________ авыл җирлегенең ___________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе турында»**
**Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районы _____________ авыл җирлеге Башлыгының ______ елның _____ _____________ ___ номерлы карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, __________________ муниципаль районы (« _________________ шәһәре» муниципаль берәмлеге), ________________ авыл җирлеге Уставының ______ нче маддәсе нигезендә, _______________ муниципаль районы __________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы **КАРАР ИТТЕ:**

***1.*** __________ муниципаль районы ________________ авыл җирлеге («__________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) _____________ торак пунктында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** ______ елның ______________ 00 сәг. 00 мин.билгеләргә.

***2.*** __________ муниципаль районы ________________ авыл җирлеге («__________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) _____________ торак пунктында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** ______ елның ______________ 00 сәг. 00 мин.билгеләргә.

***3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакытлыча яки башка билгеләр буенча) муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.***

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 20_______ елда __________муниципаль районы __________авыл җирлеге («__________шәһәре» муниципаль берәмлеге) ___________ территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә ____________________________________________(үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә) тыш, _______ сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча тотуга ризамы?

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып ___ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы _____________ ФИО ________

**Проект**

Татарстан Республикасы ____________
муниципаль районы ________________
авыл җирлеге составына керүче
(«___________ шәһәре» муниципаль
берәмлеге) торак пунктларда гражданнар
җыены турындагы Нигезләмәгә
**8 нче кушымта**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ ПРОТОКОЛЫ

________________________________________________________
(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәг. 00 минут № _____

Катнаштылар _____________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыелышында рәислек итүче __________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)

Гражданнар җыелышы сәркатибе _________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)

## КӨН ТӘРТИБЕ

1.

2.

## ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:

1. ______________________________________________

Тавыш бирү нәтиҗәсе:
«Әйе» ____ кеше.
«Юк» ____ кеше.

## ҖЫЕН СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:

**Рәис итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?
__________________________________ **сәркатип итеп сайлау тәкъдиме бар.**
(ФИО)

Тавыш бирү нәтиҗәсе:
«Әйе» - ____ кеше.
«Юк» ____ кеше.

## ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

**Рәислек итүче**: гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

1. Хисап комиссиясе рәисе итеп ________________________________________

һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:
2. ______________________________
3. ______________________________

Тавыш бирү нәтиҗәсе:
«Әйе» ____ кеше.
«Юк» ____ кеше.

КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ (вариант буларак тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә)

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырый.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«ӘЙЕ» - ____ кеше.
«ЮК» ____ кеше.

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
______________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язылуы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР :** (содержание решения)

Тавыш бирү нәтиҗәсе: «Әйе» - ____ кеше.
«Юк» - ____ кеше.

Карар ___________________________
Кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
______________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме )
(чыгышның кыскача язылуы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәсе: «Әйе» - _____ кеше.
«Юк» - _____ кеше.

Карар ___________________________
Кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ___________________
(имза) (имза расшифровкасы)
СекГражданнар җыены сәркатибе __________ ___________________
(имза) (имза расшифровкасы)

**Гражданнар җыенын этаплап үткәргән очракта**

**Проект**
Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районы (муниципаль берәмлек «шәһәр ________________») __________________авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турындагы Нигезләмәгә **9 нчы Кушымта**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ ПРОТОКОЛЫ**

________________________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәг. 00 минут № __1___

Катнаштылар: _____________________________________________________ кеше.
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыены рәисе ________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
Гражданнар җыены сәркатибе _________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ::**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

________________________ – ____________________

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» - ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

_________________________________ _______________________
(ФИО) (вазифа)
җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәсе:
«Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ________________________________ һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:

_____________________________________

_____________________________________

Тавыш бирү нәтиҗәсе
«Әйе» ____ кеше.
«Юк» ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ: (вариант буларак: тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә)**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырый.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» - ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
__________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язу яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. __________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язылуы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**Хәл иттеләр : (хәл итү эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше.
«Юк» - ____ кеше.

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
**______________________________________________________**
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язу яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. **________________________________________________________**
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язылуы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Хәл иттеләр: (хәл итү эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәсе «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе Гражданнар Җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча ______________________ җирлегенең Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка җиткереләчәк).**

Гражданнар җыены рәисе __________ ___________________
(имза) (имза расшифровкасы)

Гражданнар җыены сәркатибе __________ ___________________
(имза) (имза расшифровкасы)

**Гражданнар җыенын этаплап үткәргән очракта**

**Проект**

Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районы (муниципаль берәмлек «шәһәр _________________») __________________авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турындагы нигезләмәгә 10 нчы Кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫ ПРОТОКОЛЫ**

________________________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәг. 00 минут № __2___

Катнаштылар: ____________________________________________________ кеше.

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыены рәисе ________________________________________________

(фамилия, исеме, әтисенең исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе __________________________________________

(фамилия, исеме, әтисенең исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

2. ________________________ – ____________________

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

__________________________________ ________________________

(ФИО) (вазифа)

җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәсе:
«Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ________________________________ һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:

______________________________________

______________________________________

Тавыш бирү нәтиҗәсе
«Әйе» ____ кеше.
«Юк» ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ: (вариант буларак: тавыш бирү формасы гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә)**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырый.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» - ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
__________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язу яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. __________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язылуы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**Хәл иттеләр : (хәл итү эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше.
«Юк» - ____ кеше.

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
____________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язу яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ____________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язылуы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Хәл иттеләр: (хәл итү эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәсе «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе Гражданнар Җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча ____________________ җирлегенең Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка җиткереләчәк).**

Гражданнар җыены рәисе _________ __________________
(имза) (имза расшифровкасы)

Гражданнар җыены сәркатибе _________ __________________
(имза) (имза расшифровкасы)

ПРОЕКТ
Татарстан Республикасы ____________
муниципаль районы ________________
авыл җирлеге Советы
«___» ________________ 20___ ел
______ сессиясенең ______ нче
номерлы карарына **11 нче кушымта**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ УЗДЫРЫЛГАН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ҖЫЕННЫҢ ЙОМГАКЛАУ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль районы торак пункты исеме)

«______» _________ 20__ ел 00 сәг. 00 минут №____

____ 20__ ел № 1 гражданнарның беренче этабы беркетмәсе нигезендә ______________________________ (рәислек итүче ФИО), ____ 20__ ел № 2 гражданнарның икенче этабы беркетмәсе нигезендә______________________________ (рәислек итүче ФИО) һ.б. ________________________________________________________ мәсьәләсе буенча гражданнарның этаплап җыеннары үткәрелде

1. Җыенның үткәрелгән этапларының тавыш бирү формасы (ачык, яки ябык (яшерен) күрсәтелеп саны)_______
2. Гражданнар җыеннарының этаплап уздырыла торган беркетмәләре саны ______
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аларның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;
4. Сайлау хокукына ия һәм гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны_________

**КАРАР ИТТЕЛӘР: (Карар эчтәлеге)**

- Гражданнар җыены этапларында кертелгән мәсьәлә өчен (ӘЙЕ) бирелгән тавышларның гомуми саны _________;
- Гражданнар җыены этапларында кертелгән мәсьәлә өчен (ЮК) бирелгән тавышларның гомуми саны _______

**КАРАР: кабул ителде (кабул ителмәде, сәбәпләрен күрсәтеп)**

Рәислек итүче (Авыл җирлеге Башлыгы): ______ _________ _______
(имза) (имза расшифровкасы)

Сәркатип: _________ _______________________
(имза) (имза расшифровкасы)

**П р о е к т**
**1 2 н ч е К у ш ы м т а**

**Г Р А Ж Д А Н Н А Р Җ Ы Е Н Ы Н Ы Ң И К Е Н Ч Е Э Т А Б Ы Х И С А П К О М И С С И Я С Е П Р О Т О К О Л Ы**

Татарстан Республикасы _________________ муниципаль районы __________________ авыл җирлеге составына керүче ____________________ торак пунктында тавышларны санау нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел

№ 1

______________________________
(торак пункт исеме)
Татарстан Республикасы
___________ муниципаль районы
___________авыл җирлеге

**Катнашучылар**: Хисап комиссиясе әгъзалары:

1. ФИО;
2. ФИО;

һ.б.

Халык җыенында сайлау хокукына ия булган ____ кеше катнаша (катнашты).

Гражданнар Җыенының икенче этабындагы көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«_____________________________________________________________________________»

**ӘЙЕ___________тавыш**

**ЮК_________тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИО
Хисап комиссиясе әгъзалары

ФИО

ФИО

**П р о е к т**
**1 3 н ч е К у ш ы м т а**

**Г Р А Ж Д А Н Н А Р Җ Ы Е Н Ы Н Ы Ң И К Е Н Ч Е Э Т А Б Ы Х И С А П К О М И С С И Я С Е П Р О Т О К О Л Ы**

Татарстан Республикасы _________________ муниципаль районы __________________ авыл җирлеге составына керүче ____________________ торак пунктында тавышларны санау нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел                                                  № 2

______________________________
(торак пункт исеме)
Татарстан Республикасы
_____________ муниципаль районы
_____________авыл җирлеге

**Катнашучылар**: Хисап комиссиясе әгъзалары:
1. ФИО;
2. ФИО;
һ.б.

Халык җыенында сайлау хокукына ия булган ____ кеше катнаша (катнашты).

Гражданнар Җыенының икенче этабындагы көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«_______________________________________________________________________________»

**ӘЙЕ___________тавыш**

**ЮК_________тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИО
Хисап комиссиясе әгъзалары
ФИО

ФИО

Татарстан Республикасы ________________
муниципаль районы ____________________
авыл җирлеге Советының
201__ елның «___» _______________
______сессиясенең ______ нче номерлы
карарына кушымта **14 нче Кушымта**

**ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ**
**Татарстан Республикасы _________________ муниципаль районы ________________ җирлегендә Гражданнар Җыенының беренче, икенче һәм (һ.б) этаплары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында**

«___» ____________ 20__ ел ___________________________________
(торак пунктның исеме)

Гражданнар Җыенының беренче, икенче (һ. б.) этаплары нәтиҗәләре
_________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек территориясе яисә аның өлеше исеме)
территориясендә үткәрелгән Гражданнар Җыенының беренче, икенче (һ. б.) этаплары нәтиҗәләре

Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү датасы һәм вакыты: _______________
_____________ 20__ ел.
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
сораулары буенча гражданнар җыеннарында бирелгән тавышларын санау нәтиҗәсендә
**Хисап комиссиясе түбәндәгеләрне билгеләде:**

1. Халык җыенының үткәрелгән этаплары саны ________________________________________;
2. Халык җыенының үткәрелгән этаплары буенча Хисап комиссиясенең бирелгән беркетмәләр саны ___________________;
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны __________;
4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________________;
5. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә өчен бирелгән **ӘЙЕ** тавышларының гомуми саны _______;
6. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә өчен бирелгән **ЮК** тавышларының гомуми саны _______;.

**Карар иттеләр:**

1. _________________ мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә _____________________ мәсьәләсе буенча җыен карарын кабул ителгән дип санарга.
2.

Хисап комиссиясе рәисе _____________________ _______________
(фамилия, инициаллары)
(имза)

Хисап комиссиясе әгъзалары 1. ___________________________ _______________

(фамилия, инициаллары) (имзалары )

2. ___________________________ _______________

Беркетмә төзелде «___» ______________ 20___ ел

**Проект**
Татарстан Республикасы
______________муниципаль районы
___________________ авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм
уздыру тәртибе турында нигезләмәгә
**1 нче Кушымта**

КУЛТАМГА

Без, түбәндәге кул куючылар, ___________________________________муниципаль
(муниципаль берәмлек, __________________«шәһәре»)
районы _______________________ авыл җирлегенең _____________________ торак пунктында түбәндәге сорауларны карау өчен _____________________________________
(гражданнар җыенын үткәрү вакыты)
гражданнар җыены үткәрү инициативасын хуплыйбыз:

_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
(сораулар)

| № № п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне | Яшәү урыны адресы | Пасорт сериясе, номеры, алмаштыручы документ | Имза датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Култамганы раслыйм ___________________________________
(имза җыючының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне,
_________________________________________________________________
паспорт сериясе һәм номеры, яки алмаштыручы документ)
____________________ (имза һәм дата)

**Гражданнар җыенын инициатив төркем инициативасы белән чакырган очракта**

**Проект**
Татарстан Республикасы
______________муниципаль районы
___________________ авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру
тәртибе турында нигезләмәгә
**2 нче Кушымта**

# КАРАР

**_______ 20__ ел** **№ ____**

**________________ муниципаль районы ________________ авыл җирлегенең ________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, ________________ авыл җирлеге (шәһәр округы) Уставының _______ статьясы, ____________ муниципаль районы ______________ авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 20____ елның ___________ _____ сәгать ______ минутка ___________ муниципаль районы _________ авыл җирлегенең ___________ торак пунктында ____ үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. 20____ елның ___________ _____ сәгать ______ минутка ___________ муниципаль районы _________ авыл җирлегенең ___________ торак пунктында ____ үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 20_______ елда __________муниципаль районы __________авыл җирлеге («___________шәһәре» муниципаль берәмлеге) ___________ территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә)_____________________________________________тыш, _______ сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча тотуга ризамы? »

«ӘЙЕ» «ЮК»

4. 4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында _____________________ кабул ителгән көннән соң _____ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

____________________ ФИО _____________________
җирлеге Советы рәисе

**Проект**

Татарстан Республикасы _____________ муниципаль районы («___________________шәһәре» муниципаль берәмлек) ________________ авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы Нигезләмәгә **3 нче Кушымта**

**«_____ _____ ____ муниципаль районы («__________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) _________ ____ авыл җирлегенең ______ ____ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе турында» Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районы («___________шәһәре» муниципаль берәмлеге) _____________ авыл җирлеге Башлыгының ______ елның _____ октябрендәге ___ номерлы карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», _____________ ____ муниципаль районы («______________ _____ шәһәре» муниципаль берәмлеге») ________________ авыл җирлеге Уставының ____ статьясы нигезендә, ______________ муниципаль районы («_________________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) _____________ авыл җирлеге Башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

20____ елның ____________ ______ сәгать ______ минутка ____________ муниципаль («_____________ шәһәре» муниципаль берәмлеге) районы _________ авыл җирлегенең ___________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә

.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 20_______ елда __________муниципаль районы __________авыл җирлеге («___________шәһәре» муниципаль берәмлеге) ___________ территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә)_____________________________________________тыш, _______ сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча тотуга ризамы? »

« Әйе» «Юк»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң __________ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы _____________ ФИО ______________

**Проект**

Татарстан Республикасы _____________ муниципаль районы (муниципаль берәмлек « _____________________ шәһәре ») _______________авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәгә **4 нче Кушымта**

___________________________ муниципаль районы ___________________ авыл җирлегенең ___________________ торак пунктында теркәлгән сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлеге «___» _________________ 20___ел.

| №№ | Фамилия, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшь тулганнарга туган датасы) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Җыен рәисе _________________ ______________________
(имза) (Фамилиясе, инициаллары)

Җыен сәркатибе _________________ ______________________
(имза) (Фамилиясе, инициаллары)

**Проект**

Татарстан Республикасы _____________ муниципаль районы (муниципаль берәмлек «шәһәр _________________») ___________________авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турындагы нигезләмәгә 7 нче Кушымта

Татарстан Республикасы _________________________ муниципаль районы _______________________ авыл җирлеге составына керүче _____________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү

**БЮЛЛЕТЕНЕ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә сорауның эчтәлеге | «Әйе» | ☐ |
| | «Юк» | ☐ |
| | | |